ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2022 Олы Кайбыч ав. 19

2022 елга халыкка күрсәтелә торган торак
хезмәтләренә тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең иң чик (максималь) индекслары турында» 2021 елның 15 декабрендәге ПУ-958 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре тарифларын кушымтада каралганча билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен тарифларны раслау турында» 2021 елның 15 гыйнварындагы 1 номерлы карарын.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «26» 01
19 номерлы карарына
кушымта

**2022елның 1 гыйнварыннан 2022елның 31 декабренә кадәр халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар**

| т/б № | Түләү атамасы | Хезмәт үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 30 июненә кадәр | 2022 елның 1 июленнән 2022 елның 31 декабренә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,79 | 0,82 |
| 2 | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | 3,29 | 3,42 |
| 3 | Йорт эчендәге су үткәргеч-канализация челтәрләренә агымдагы ремонт һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 2,11 | 2,20 |
| 4 | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 1,14 | 1,19 |
| 5 | Наем буенча база ставкасы | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 5,00 | 5,00 |
| 6 | Тышкы фасад эчендәге газүткәргечләргә техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 0,52 | 0,54 |
| 7 | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 1,12 | 1,16 |
| 8 | Җилләтү каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 2,20 | 2,30 |